ГЛАВА ПЕТРОВСКО-ЗАВОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕТРОВСКИЙ ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 ел, 07 ноябрь № 8

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Мостафин авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мостафин авылы гражданнары җыенын медпункт бинасында 2024 елның 23 ноябренә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкән кешеләр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан кала, Петровский Завод авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2024 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Мостафин торак пунктында урам яктырту челтәрләрен (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау;

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Мостафин торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча йортуче хезмәтләренә түләү);

3. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Мостафин торак пунктында һәйкәл төзү һәм янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү – материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Мостафин торак пункт территориясендә улән чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү); триммер өчен, запас частьләр, чыгым материаллары, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторны тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча йөртүче хезмәтләре өчен түләү);
5. Мостафин торак пунктында ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратка кадәр керү юлын төзү - вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча түләү)

ӘЙЕ ЮК?».

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә игълан итәргә.

Петровский Завод
авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Нуртдинов